**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**БИЕКТАУ**
**МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**ШӘПШИ АВЫЛ**
**ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**
422708, Татарстан Республикасы, Биектау районы,
Шәпши авылы, Ленин урамы, 1

**СОВЕТ ШАПШИНСКОГО**
**СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**
**ВЫСОКОГОРСКОГО**
**МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**
**РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
422708, Республика Татарстан, Высокогорский район,
с. Шәпши, ул. Ленина, 1

тел./факс 8(84365) 77-2-36,e-mail:Shap.Vsg@tatar.ru

---

**КАРАР** **РЕШЕНИЕ**
**28.11. 2019 ел** **№ 170**

**Биектау муниципаль районы Шәпши авыл җирлеге җирле үзидарә органнарының Биектау муниципаль районы җирле үзидарә органнары белән вәкаләтләрнең бер өлешен тапшыру (кабул итү) турында килешүләр төзү тәртибен раслау турында**

“Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында”, 2003 ел, 6 нчы октябрь, 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы 4 бүлеге, “Биектау муниципаль районы Шәпши авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Шәпши авыл җирлеге Советы,

**КАРАР ИТТЕ:**

1. Теркәлгән Биектау муниципаль районы Шәпши авыл җирлеге җирле үзидарә органнарының Биектау муниципаль районы җирле үзидарә органнары белән вәкаләтләрнең бер өлешен тапшыру (кабул итү) турында килешүләр төзү тәртибен расларга.
2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы рәсми сайтында Интернет челтәрендә http://vysokaya-gora.tatarstan.ru/ веб-адресы буенча һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча урнаштырып халыкка җиткерергә.
3. Әлеге карар рәсми рәвештә бастырылып чыкканнан соң (халыкка җиткерелгәннән соң) үз көченә керә.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Совет рәисе,
авыл җирлеге башлыгы В.А.Беляков

Кушымта
Расланагн
Татарстан Республикасы
Биектау муниципаль районы
Шәпши авыл җирлеге Советы
карары белән
28.11.2019 № 170

**Шәпши авыл җирлеге җирле үзидарә органнарының Биектау муниципаль районы җирле үзидарә органнары белән вәкаләтләрнең бер өлешен тапшыру (кабул итү) турында килешүләр төзү тәртибе**

**1. Гомуми нигезләмәләр**

1.1. Әлеге Шәпши авыл җирлеге җирле үзидарә органнарының Биектау муниципаль районы җирле үзидарә органнары белән вәкаләтләрнең бер өлешен тапшыру (кабул итү) турында килешүләр төзү Тәртибе “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында”, 2003 ел, 6 нчы октябрь, 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы 4 бүлеге (алга таба - “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” Федераль закон), “Биектау муниципаль районы Шәпши авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә эшләп чыгарылган һәм Шәпши авыл җирлеге җирле үзидарә органнарының Биектау муниципаль районы җирле үзидарә органнары белән вәкаләтләрнең бер өлешен тапшыру (кабул итү) турында килешүләр төзү тәртибен җайга сала (алга таба - Килешү).

1.2. Шәпши авыл җирлеге җирле үзидарә органнары (алга таба – Җирлек) Биектау муниципаль районы җирле үзидарә органнары (алга таба – район) белән Җирлек бюджетыннан район бюджетына бирелә торган бюджетара трансфертлар хисабына, аларга үз вәкаләтләренең кайбер өлешен тормышка ашыруны тапшыру буенча Килешүләр төзергә хокуклы.

Бу очракта районның җирле үзидарә органнары җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итү буенча вәкаләтләрне, “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” Федераль закон, район Уставы, җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итү буенча җирлеккә вәкаләтләрне тапшыру турында Килешү нигезендә тормышка ашыралар.

1.3. Район җирле үзидарә органнары Җирлекнең җирле үзидарә органнары белән район бюджетыннан җирлекләрнең бюджетларына бирелә торган бюджетара трансфертлар хисабына, аларга үз вәкаләтләренең кайбер өлешен тормышка ашыруны тапшыру турында Килешү төзергә хокуклы.

Бу очракта Җирлекнең җирле үзидарә органнары җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итү буенча вәкаләтләрне, “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” Федераль закон, Җирлек Уставы, җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итү буенча вәкаләтләрне тапшыру турында Килешү нигезендә тормышка ашыралар.

## 2. Җирлекнең җирле үзидарә органнары компетенциясе

2.1. Җирлек Советы:

1) вәкаләтләрнең бер өлешен җирлектән муниципаль районга бирүнең инициаторы;

2) җирлекнең җирле үзидарә органнарының район җирле үзидарә органнарына һәм киресенчә, вәкаләтләрнең бер өлешен кабул итү (бирү) турында карар кабул итә;

3) кабул ителгән карарларның башкарылуын контрольдә тота;

4) җирлекнең районнан кабул ителгән вәкаләтләрен тормышка ашыру мәсьәләләре буенча норматив хокукый актларны кабул итә, башкасы Килешү белән каралмаган булса.

2.2. Җирлек башкарма комитеты:

1) вәкаләтләрнең бер өлешен җирлектән муниципаль районга бирүнең инициаторы.

## 3. Җирлек җирле үзидарә органнары тарафыннан вәкаләтләрнең бер өлешен район җирле үзидарә органнарына тапшыру

3.1. Җирлек вәкаләтләренең бер өлешен тапшыруның инициаторы булып Җирлек җирле үзидарәсе органы була ала.

3.2. Җирлек җирле үзидарә органы вәкаләтләрнең бер өлешен тапшыру турында карар проектын Җирлек Советы рәисенә чираттагы утырышта каралыр өчен җибәрә.

3.3. Вәкаләтләрнең бер өлешен тормышка ашыруны тапшыру турында карар проекты Җирлек Советы рәисе тарафыннан каралыр өчен Җирлек Советына кертелә. Җирлек Советы вәкаләтләрнең бер өлешен район җирле үзидарә органнарына тапшыру турында карар кабул итә һәм кабул ителгән карарны район җирле үзидарә органнарына каралу өчен җибәрә. Җирлек Советы карарында җирле әһәмияткә ия мәсьәләләр составына керүче бирелә торган вәкаләтләр күрсәтелә.

3.4. Җирлек Советы тарафыннан карар проектын карауның уңай нәтиҗәсе һәм Район Советы карары булганда, район җирле үзидарә органы һәм җирлекнең җирле үзидарә органы арасында Килешү төзелә.

3.5. Әгәр дә Совет депутатлары вәкаләтләрнең бер өлешен тапшыру турында карар проектын кире каккан очракта, инициатива юллаган җирле үзидарә органнарына алар цинициатор булган мәсьәләләр нәтиҗәләре буенча хат җибәрелә.

3.6. Килешү белән күз алдында тотылган вәкаләтләрне башкаруны контрольдә тоту, Җирлеккә вәкаләтләрне тормышка ашыру, финанс чараларын куллану (бюджетара трансфертлар) турында хисаплар тәкъдим итү юлы белән тормышка ашарыла. Хисаплар тәкъдим итүнең периодиклыгы Килешү белән билгеләнә.

3.7. Килешү белән күз алдында тотылган вәкаләтләрне башкару өчен кирәкле финанс чаралар, бюджетара трансфертлар рәвешендә биреләләр.

## 4. Җирлек җирле үзидарәсе органнарының район җирле үзидарәсе

**органнарыннан вәкаләтләрнең бер өлешен кабул итү**

4.1. Район вәкаләтләренең бер өлешен алуның инициаторы булып район җирле үзидарәсе тора.

4.2. Җирлек җирле үзидарәсе органнары районның җирле үзидарә органнарыннан җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итү буенча вәкаләтләрнең бер өлешен кабул итү инициативасы белән чыгарга мөмкин. Вәкаләтләрне кабул итү буенча тәкъдим район җирле үзидарә органы адресына вәкаләтләрне тапшыру турында мәсьәләне карау өчен юллана һәм күрсәтелгән орган тарафыннан 30 календарь көннән дә артмаган срокта каралырга тиеш.

4.3. Вәкаләтләрне тапшыру турында тәкъдим и кабул ителгән очракта, район Советы тарафыннан район җирле үзидарәсе органнары вәкаләтләренең бер өлешен җирлек җирле үзидарәсе органнарына тапшыру турында карар кабул ителә.

4.4. Кабул ителгән карар Җирлек адресына җибәрелә һәм анда тапшырыла торган вәкаләтләр турында, вәкаләтләрне тормышка ашыруга бирелә торган финанс чаралар турында мәгълүматлар булырга тиеш.

4.5. Совет тарафыннан кабул ителгән карар район җирле үзидарә органнарына җибәрелә.

Җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне чишү буенча вәкаләтләрнең бер өлешен кабул итү турында мәсьәләне карау уңай хәл ителгән очракта, җирлекнең һәм районның вәкиллекле органнары, билгеле җирлек җирле үзидарәсе органнары һәм район җирле үзидарәсе органнары арарсында Килешү төзелә.

**5. Килешүнең эчтәлегенә таләпләр**

5.1. Килешүләр билгеле бер вакытка төзелә, аларның эшчәнлеге нигезләрен һәм тәртибен үз эченә алган нигезләмәләр булырга тиеш, шул исәптән вакытыннан алда туктату, бирелә торган вәкаләтләрне тормышка ашыру өчен бюджетара трансфертларның еллык күләмен ачыклау тәртибе, шулай ук килешүләрне үтәмәгән өчен финанс санкцияләрне күз алдында тоту.

5.2. Килешү җирлек һәм район җирле үзидарә органнары өчен имза куелган көннән соң үз көченә керә һәм үтәү өчен мәҗбүри була.

**6. Килешүнең гамәлдән чыгуы**

6.1. Килешү ул төзелгән срок чykkаннан соң, гамәлдән чыга.

6.2. Шартларны үтәмәгән очракта Килешү теләсә кайсы як инициативасы белән өзелергә мөмкин. Килешүне өзү турында хәбәрнамә язма формада, өзү датасына кадәр 30 календарь көннән дә соңга калмыйча җибәрелергә тиеш.